Рәфис
Мөхәммәтдинов

Кәүсәрия
Шафикова

# БӨРЕЛӘР АЧЫЛГАНДА

ЯҢАВЫЛ
2000

Рәфис Мөхәммәтдинов
Кәүсәрия Шафикова

# БӨРЕЛӘР АЧЫЛГАНДА

Яңавыл
2000



# Авторлар сүзе

Без Башкортстандагы Яңавыл районының Исәнбай авылында яшәүче Кәүсәрия Фидаи кызы Шафикова һәм шул ук районның Яңа Уртавыл авылында яшәүче Рәфис Мөхәммәтдинов. Бала чактан ук аякларга басып йөри алмасак та, бу тормыштагы ямьне, матурлыкны күреп, тоеп яшәвебез белән бәхетлебез. Әлбәттә, тормыштагы ямьсезлекләр безне борчый. Матурлык күбрәк булсын иде дип, үзебездән дә бер гүзәллек өстәлсен өчен кулыбызга каләм алдык. Авыр язмыштан уфтанып яшәү безгә хас түгел! Инде 1997 елдан никахлы булсак та бергә яши алмыйбыз, туганнарыбыз ярдәме белән очрашып торабыз. Көннәрне телефоннан сөйләшеп үткәрәбез. Кайгы-шатлыкларыбыз уртак!

Рәфис Мөхәммәтдинов

# КУЛЫМДА КАУРЫЙ КАЛӘМ

# Хөрмәтле китап сөючеләр!

Бу китапны кулыгызга алу белән аның авторлары кем икәнлеген бик тиз танырсыз. Аз гына вакыт эчендә үзләренең киләчәккә өмет белән караучы шигырьләре белән кешеләр күңеленә үтеп керделәр. Алар - Рәфис белән Кәүсәрия.

Чираттагы бу китаплары да тормышка аек акыл белән караучы, гади укучылар күзенә чагылмый калган матурлыкны, изгелекне сиземләп, кешеләргә күрсәтеп бирүче шигырьләр белән тулы.

Шагыйрьләр дә, язучылар да күпләп тумыйлар. Кеше үзен чолгап алган тирәлектәге кире күренешләрне күреп, аларны тыныч кына узып китә алмаса, башкаларның маңгай күзләре күрә алмый торган гүзәллекне күңел күзләре белән күреп, кулларына "каурый каләм" алып, башкаларга җиткерә алса, андый кешеләрне шагыйрь диләр.

Рәфис белән Кәүсәриянең шигырьләре дә нәкъ менә шундый сыйфатларга ия. Аларның иҗат җимешләре дә, үзләренең язмышлары кебек авазлашлар. Ләкин алар берсен берсе кабатламыйлар. Һәр кайсысының үз алымы бар.

Бу китап әле соңгысы булмас. Алар безне үзләренең иҗаты белән заманыбызның барлык күренешләрен чагылдырган яңадан-яңа әсәрләре белән шатландырырлар дигән өметтә калабыз.

Низам Хәмзин,<br>
Нефтекама "Инеш"<br>
иҗат берләшмәсе җитәкчесе.

# Тирәк

Алларымда җил-давылга
Бөгелә бер тал-тирәк.
Бу кадәрле давылларга,
Сынмый түзәргә кирәк!

Бөгелсә дә, сыгылса да,
Түзә шул, түзә тирәк.
Әйтерсең ул авырлыкны
Кичерә минем йөрәк!

# Таркалдылар

“Тиң булмады, аерылабыз инде
Күпме була болай түзәргә.
Балам нәни чакта ирем белән
Араны, дим, кирәк өзәргә.

Ялгызыма тормыш авыр булса,
Парын табып, бәлки, чыгармын.
Ул алкашка тынгы бирәмме соң,
Алиментын күпләп сыгармын!”

Бер яшь ханым шулай күкрәк киереп,
Тирә-юньгә чәчте зәһәрен.
“Тик балама гына ата булмас!”-
Дип әйтмәде бер сүз каһәрең.

Таркалдылар, бала ятим калды.
Төп сәбәбе моның - эчкелек.
Әле һаман җәмгыятебездә
Хөкем сөрә нинди көчсезлек!

# Туган ягыма

Туган ягым, синең һәрбер кешең
Якын туганымдай ягымлы.
Акчарлаклы Бүә елгасы да
Монда тып-тын гына агымлы.

Туган авылыма янәш кенә
Сакат, Очлы, Мөнир таулары.
Талгын җилләрдә дә ишетелә
Кичен урманнарның шаулавы.

Басу-кырларыбыз мул уңышлы,
Бар дистәләп чишмә-инеше.
Авызыңда тотып тора торган
Туфрагыңда үскән җимешең.

Авылымның гүзәллеген күреп,
Яши-яши тәмам соклана м.
Туган ягым, дөньялыкта синнән
Яшәргә көч, илһам, дәрт алам!

***

## /апама/

Җәйләрнең иң җылы, кояшлы,
Чәчәкле аенда тугансың.
Әткәйгә, әнкәйгә һәм безгә,
Бер генә кыз бала булгансың.

И гомер дигәнең, аккан су,
Син инде иллегә җиткәнсең.
Шул уңай, зур табын әзерләп,
Энеңнәр килгәнен көткәнсең.

Изгелек кылучы фәрештә
Булдың син гомергә зур терәк.
Ишетче, йөрәкләр тибәләр,
Безгә бит, апам, син гел кирәк!

Гаиләңә күз генә тимәсен.
Гел шулай шатланып яшәгез.
Балалар кайгысын күрмичә,
Эшләрең уң булып, авырмый,
Бәхетле яшә, дип дәшәбез!

# Юк, башымны имәм

Ходай миңа каты сынау биргән,
Хәрәкәтсез аяк-кулларым.
Кеше ярдәменнән тыш кабалмыйм,
Авызыма тәгам суларын.

И Ходаем, күпме каһәрләмә,
Башымны һич түбән имәмен.
Бу дөньяда аяк-куллыларның
Моң-зарларын ишетүе авыр.
Мин “бәхетсез булдым”, димәмен.

# Гомер телим

Тәрәз төпләрендә гөлләр үсә,
Чәчәкләрнең төсе төрлечә.
Үсәр идемени алар шулай,
Әнкәй, синең кулың тимичә!

Көн дә сулар сибеп, тәрбияләп
Үстерәсең саклап, кадерләп.
Кошлар кебек үсеп таралышкан,
Нарасыйларыңны хәтерләп.

Туган нигездәге гүзәллекнең
Чикләмәсен Ходай көннәрен.
Озак еллар, тагын озак еллар,
Чәчәк атсын, әнкәй, гөлләрең!

# Авылыма

Туган авылым, Яңа Уртавылым,
Кояш илем минем, гөл илем.
Синдә тудым, синдә гомер итәм,
Назлап-назлап сөя таң җилең.

Кайгыларым, шатлыкларым синдә,
Мәгълүм аның сиңа барчасы.
Тирә-якларыңда елга-күлләр,
Урман, таулар, җимеш бакчасы.

Исемең дә җисемеңә килә.
Яңарасың, авылым, көн саен.
Сине ташлап читкә киткәннәр дә
Эзли кире кайтыр бер җаен.

Туган авылым, Яңа Уртавылым,
Колачың киң, әйдә кайтсыннар.
Хаталарын аңлап, кире кайтып,
Бәхетләрен синдә тапсыннар!

# Бәхет нуры

Кырга чыктым август иртәсендә,
Хуш ис аңкый иркен кырларда.
Кыр-кораблар килә тезелешеп,
Штурваллар тырыш кулларда.

Таң җилләре тулы башакларны,
Талгын гына итеп тибрәтә.
Тышта челлә, көннәр бигрәк бөркү,
Игенчегә авыр, тирләтә.

Шул тир белән салган орлыклардан
Мул уңышлар җиткән өлгереп.
Күрәм, әнә сезнең хезмәт бит ул,
Бәхет нуры тора бөркелеп.

# Карлар ява

Ябалаклап ап-ак карлар ява,
Тирә-юньдә шундый матурлык.
Мамыктан пакь шушы ак карларны
Түшәк итеп кенә ятарлык.

Шушы кадәр аклык-сафлыкларга
Басарга да хәтта кыймассың.
Бәс ябынган агачларны күзләп
Гомерең буена да туймассың.

Карлар ява, ап-ак карлар ява.
Яусын әйдә, яусын шатлыкка.
Тормыштагы булган пычраклыклар
Бетсен әле күмелеп аклыкка!

* * *

Илемә илле бишенче
Яз килә, Җиңү язы!
Әмма нигәдер күңелдә
Юк бер дә шатлык назы.

Ветераннар җанында да
Борчулы уйлар янә.
Самолетлар ил өстенә
Бомба ташлый бит, әнә!

Чечня җирендә зур сугыш,
Күпме кеше газабы.
Кайчан булыр бу мәхшәрнең,
Булыр микән азагы?

Халкым фашистны җиңгән бит,
Тынычлык булсын өчен.
Киләчәктә мәңге-мәңге,
Ал таңнар тусын өчен!

Нигә сугышабыз?

# Җиңәргә!

Шундый чаклар була бик еш кына,
Дөньялыктан туеп куясың.
Дуамаллык белән җиңел уйлап,
Жаннарыңны, кешем, кыясың.

Шатлыклардан гына тормый тормыш,
Төрле чаклар булып куйгалый.
Әле күңел күгең аяз булса,
Әле кара болыт оялый.

Тормыш булгач була төрле чагы,
Авырлыклар төшә иңнәргә.
Бу дөньяда без бит кунак кына,
Авырлыкны кирәк җиңәргә!

# Яшә!

## /Кәүсәриягә/

Ярты гасыр элек тавыш биреп,
Фани дөньяга син тугансың.
Алтын көздә тугангамы әллә,
Алтыннан да алтын булгансың.

Рәхмәтем зур, сине бу дөньяга
Бүләк иткән атаң-анаңа.
Язгы ташкыннардай йөрәгеңнән,
Ургып-ургып ярсып моң ага.

Халык өчен, һәрчак сафлык өчен,
Яшәүләрең синең җан атып.
Күңелләргә ятыш иҗатыңны
Кабул итә халкым яратып.

Көтсен әле алда сине тагы
Уңышларның иң-иң зурлары.
Яшә әле, озак еллар яшә,
Сибеп безгә алтын нурлары!

# Туган көнем

Туганнарым, салкын кыш көнендә
Мондый бүләк кайдан таптыгыз?
Янып торган тере чәчәк тотып,
Бәйрәмемә минем кайттыгыз.

Бүләгегез белән бар күңелем
Дөньяларын әсир иттегез.
Сез бит миңа февраль аенда ук
Җәйләр бүләк итеп киттегез.

Беләм, тере чәчәк күп тә тормый,
Сулачагын аның янымда.
Сезнең хөрмәтегез бәйрәм булып
Гомерлеккә калыр җанымда.

* * *

Зурларга охшарга теләп
Бала рюмка тота.
Алар белән чәкештереп,
Тәмле, газлы су йота.

“Карале минем дә улым
Үскән!”-дип ана көлә.
Хәзергә көләсең дә соң,
Азак еламассың микән,
Ханым?- диясем килә!

# Сәбәп

Табын корып дус-ишләрен
Кунакка дәште бер ханым.
Ун көн элек туган көнен
Юган идек бит без аның.

Аннан кызы туган көнне
Чәкәштереп бәйрәм иттек.
Елы тулган каенатасын
Шунда искә алып үттек.

Тагын нинди бәйрәм икән,
Әллә ире туган көнме?
Бүләк алып барыйм микән,
Соң, котларга анда кемне?

Баргач күрермен әле дип,
Конверт белән акча алдым.
Бу мәҗлес ни сәбәпле?
Моны белгәч хәйран калдым.

Эчкечелек чиреннән ире
Дәваланып чыккан кичә.
Шуны юу максатыннан
Ханым оештырган кичә!

# Әни

Әниемнең чәчләренә карыйм,
Сирәк кенә калган карасы.
Маңгаенда тирән буразналар,
Күргәннәрнең ачы ярасы.

Сугыш елларында үсмер кызый
Җирен сөргән, йөргән тырмага.
Җир үлчәгән, "грамм" тараткан ул,
Печән ташыган кыш фермага.

Ачлыгын да, ялангачлыгын да,
Кайгысын да күргән гомерендә.
Яу кырыннан кайткан әти белән
Гаилә корган туган җирендә.

Саф мәхәббәт җимешләре булып,
Дөньяга биш бала килгәнбез.
Килгәнбез дә шатлык кына түгел
Кайгылар да өеп биргәнбез.

Сабый чакта беребез вафат булса,
Ә мин авырыйм бала чагымнан.

Нәни тәрбиясе биреп карый,
Юк авыр сүз әни ягыннан.

Безне ташлап мәңгелеккә китте
Әтием дә якты дөньядан.
Сабыр булды, бирешмәде әни,
Нур китмәде туган оядан.

Йөзләренә ап-ак чәчкәйләре,
Биргән кебек үзгә матурлык.
Әниемнең шушы яшәү юлы,
Асылда бит олы батырлык!

# Давыллы чак

Нинди тавыш, нинди гауга
Кем талаша?
Кычкыра ханым иренә:
“Син алаша!”

Бар дөньялары да җитеш,
Йортлары яңа.
Бөтен яклап ярдәм итә
Ире аңа.

Нәрсә җитми соң боларга
Хәйран калам.
Бу хатынның сүзләренә
Колак салам.

“Бар чыгып кит, күземә дә
Һич күренмә.
Яннарымда җан көеге
Булып йөрмә.

Бер ярдәм итим димисең
Тик ятасың.

Көн дә убыр, алкаш, эчеп
Син кайтасың.

Утыным да, печәнем дә
Әзер кышка.
Рәхәтләнеп яшәрмен мин
Синнән башка!"-

Дип иренә акырды ул,
Нидер орды.
Күрше апа да боларны
Тыңлап торды.

Өзелгәндәй булды шулчак
Йөрәк кылы.
Аның да бит буй җиткергән
Бар дүрт улы!

# Мин дә бәхетле

Ак яулыклы әби үтеп бара,
Җилләр җилфердәтә яулыгын.
Карты-яше сәлам биреп уза,
Сорашалар аның саулыгын.

Авылдашлар гына түгел хәтта,
Күрше авыл таный очратып.
“Кендек әби!” диеп эндәшәләр,
Чын күңелдән аңа, яратып.

Аның ярдәмендә дөньялыкка
Тудырган бит мине әнием.
Язмышларның бәхетлесен теләп,
Кендегемне кискән әбием!

# Нишләр иде?

“Дөньядан туйдым”- ди берәү
Аек та болай үзе,
Аяк-куллары да йөри,
Исән-сау ике күзе.

Нишләр иде зәгыйфьләнеп,
Бәндәгә-бәндә калса?
Безнең кебек мәңгелеккә
Ходай урынга салса?

Җан-тәннәребез сызлауга
Учлап дару кабабыз.
Үләсе килер чакта да
Елмаеп көч табабыз!

* * *

Авыл юллары таш, асфальт,
Сукмаклары хәтфә чирәм.
Шау чәчәктә алмагачлар,
Нурлар чәчә бөтен тирәм.

Бала-чага тавышыннан
Нур өстенә ямь өстәлә.
Тагын шуны әйтә алам,
Шигыремә мин өстәмә.

Һәрбер йортка газ, су кергән,
Каладан юк һич аерма.
"Авыл" сүзен ишетүгә,
Канәгатьсез йөз җыерма.

Яшьләр китми, яши алар
Туган җирнең кадерен белеп.
Болай булгач ышанамын
Авылым калмаячак үлеп!

* * *

Шәһәрдә авылга кайтты,
Нәнәсенә кунакка.
Оныгының кайтканы юк
Иде күптән бу якка.

Кочаклашып күрештеләр
Нәнәсе белән онык.
Шулай булмый, берсен-берсе
Сагынганнар шул бик нык.

Нәнәсе сөйли татарча,
Хәлләрен сораштыра.
Малай бер җавап та бирми,
Күзенә карап тора.

Татарча сөйләшә белми
Татар баласы булып.
Аларны күзәтеп торам
Әрнеп, күңелем тулып.

# Шәһәр урамыннан барганда

Бер кардәшем әйтте бүген миңа:
“Сөйләш әле урыс телендә.
Өнәмим шушы татар телен,
Урыс теле бит ул, җиңел дә!“

Аннары ул:“гарьләндерә”, диде,
Авыл урамында түгелбез.
Бөтенесе бездән көлә сыман,
Әллә нигә шуңа күңелсез!”

“Мин гарьләнмим”, - дидем аңа карап,
Горурланам татар булганга.
Гарьләнәмен бүген синең кебек
Татарлардан урыс туганга!”

# Иртәнгә җыр

Авылыбызның җәйге таңы ата,
Кояш чыгып килә офыктан.
Юл буйлары яшел хәтфә-чирәм,
Җем-җем итеп тора саф чыктан.

Кошлар сайрый бигрәк моңлы итеп,
Йөрәкләргә керә моңнары.
Ишетелә таңда авылыбызга
Чылтырап аккан чишмә чыңнары.

Көтүченең чыбыркысы шартлый,
Яңгыратып авыл урамын.
Һәр йорт саен капка ачылганын
И шатланып карап торамын.

Таң җиленнән килә бал исләре,
Мең төр чиргә дәва алырлык.
Бер таңнары өчен генә дә, дим,
Авылыбыздан китми калырлык!

# Ямьсезлек

Урамда икәү талаша,
Әйтелә авыр сүзләр.
Чәч-башлары тузып беткән
Акаеп тора күзләр.

Бер-берсенә юл куймыйча
Бик озак талаштылар.
Телләре арып туктагач
Артларын чабыштылар.

Гыйбрәт алып үтсә иде
Күпләр болар яныннан.
Алар бит ике бөртекләр
Бер ана карыныннан.

# Эш узгач

Гөрләп яшәр чакта алар,
Һич татулык белмәде.
Урамнарга чыгып хатын
“Катсын” диеп теләде.

“Изалар чиктем гомергә,
Бер рәхәт тә күрмимен.
Җәфалауларыннан качып
Кемгә генә кермимен”

Килде ул көн, ире вафат,
Кан-яшь түгә шул ханым.
Фәрештә булган икән ич,
Хәләл җефете аның.

* * *

Гәзиттә бер сурәт, анда сабый,
Томыраеп ла карый күземә.
Матурлыкны Ходай кызганмаган,
Бу нарасыемның үзенә.

Сурәтнең аскы өлешенә
Ни язганнар, әллә хатамы?
Җаны булган ана, үз баласын
Чүп савытына соң атамы?

Хата түгел, әйе, бу чынбарлык,
Вәхшилекнең җиттек чигенә.
Сабый исән, хөкүмәтем карар.
Тик анасы ахирәткә күчкәч,
Әйтер икән җавап ни генә?

# Заман белән көрәш

“Авыл” диеп миннән көлмәсеннәр,
Сүгенәмен төрле телләрдә.
Миндәй оста итеп булдыралмый
Кызлар түгел, егет-ирләр дә!

Шәһәр кызларыннан мин киммени,
Хәмер дигәннәрен какмаска!
Бот төбеннән генә итәк киеп,
Авызыма сигар капмаска!

Төн буена урам эте кебек,
Этлек эзләп нигә чапмаска?!
Бала табып, хастаханәләрдә
Нигә әле ташлап качмаска!

Киләчәктә, наркотикларын да,
Икеләнеп тормый кадармын.
Шәһәр кызларыннан ким булмаска,
Мин барыбер җаен табармын!”

Ялгыш кына ишетәмдер моны,

Авыл кызы, юк, бу син түгел!
Җуелмаган гүзәллегең белән
Үрнәк булып шәһәр кызларына
Калуыңны тели бит күңел!

# Яңа ел каршылаганда

Яңа ел туа, яңа ел.
Гадәти генә түгел.
Яңа гасырга керәбез,
Тик иләс-миләс күңел.

Илем бүген тыныч түгел,
Дөнья болгавыр тәмам.
Туплар шартлый, кан коела,
Чечен җирендә һаман.

“Чечен бандитларын изәм,
Азаккача!” — ди урыс.
Алдын-артын чамаламый,
Тотына шул бик кырыс.

Кол булып аңа баш ияр
Милләт түгел шул Чечен!
Җаваплар бирәсе булыр,
Урыска алар өчен!

Яңа гасырга керәбез,
Ни булыр безнең өчен,
Татар, Башкортым күрмәсме,
Син күргәннәрне, Чечен?!

# Китмә, әнкәй!

Шешенгән күз кабакларың,
Авырыйсыңмы әллә, әнкәм?
Синнән калса, соң я нишләр,
Канат астындагы бәбкәң.

Болай да бит ачы язмыш
Аз тундырмый җаннарымны.
Син булганга гына җырлап,
Каршылыймын таңнарымны.

Авырмас сөякләр булмый,
Авырсаң да терел, китмә.
Әнкәм, мине канатланып
Яшәвемнән мәхрүм итмә!

* * *

Йөзләреңә карап-карап куям,
Әллә ялгыш күрәм, син түгелме.
Чибәрлегең әле кайчан гына
Әсир итә иде бит күңелне.

И кыз бала, язда кырау төшкән
Чәчәкләргә охшап калгансың шул!
Шулай булмый, син дә авызыңа
Агу тулы сигар алгансың шул!

* * *

Кичә генә кап-карадан идең,
Инде менә яшел кигәнсең.
Син җир-анам бер могҗиза инде,
Башка сиңа нәрсә диярсең!

Күпме миллион, миллиард җан иясен
Асырарга көчең җитәрлек.
Капкан тәгамнәрнең һәркайсысын
Син бирәсең, исләр китәрлек.

Ашларыңа ташлар атабыз шул,
Әнә шунысы бигрәк читене.
Өсләреңдә синең туплар шартлый,
Кан-яшь юа бүген битеңне.

Сабырлыгың, синең сабырлыгың
Әнкәйләргә генә хас инде.
Йөзләреңдә күпме тирән сырлар,
Бирешмисең, тагын яз килде!

# Чишмәләргә кушылып күңел елый

Чишмә чыңлый, чишмә гүя елый,
Күкрәп үскән талын кискәннәр.
Алар да бит якты дөньялыкта
Яшәр өчен тырышып үскәннәр.

Яшел таллар!.. Кемнең явыз эше,
Кем күтәргән икән балталар?
Экраннарда күргән яу кырларын
Хәтерләтеп алар яталар.

* * *

Берәм-берәм китәбез шул,
Мәңгелек түгел беркем.
Килер ул әҗәл дигәнең,
Мине дә алыр бер көн.

Бәлки бүген килеп алыр,
Бәлки әле күп елдан.
Тик, Ходай, соңгы көнгәчә,
Аерма мине, аерма,
Иманымнан, хак юлдан!

# Урам эте

Тәрәзәдән карап торам
Урамда йөри бер эт.
Иснәнеп чыга һәркемнең
Капка төбенә керен.

Әнә тагын берәү килә,
Эт түгел, монсы кеше.
Ишегеннән дә керетми
Куып чыгарды күрше.

Безнең дә ишекне какты,
Эчәргә эзли икән.
Әзмәвердәй бу иркәйнең
Ояты качты микән?

Мөселман кешесе бит ул,
Белә ураза ае.
Хәмергә сатар анасын
Килеп чыкса бер җае!

* * *

Яз килгән, яз, урамнардан
Гөрләвек шаулап ага.
Сыерчыклар кайтып җиткән,
Шатлыктан канат кага.

Авылкаем аларның да
Туып үскән ягы бит.
Бу мизгелләр кошкайларның
Иң бәхетле чагы бит.

Әнә күрше әбием дә
Туган җиренә кайткан
Йөзе балкый, нурлар чәчә,
Гүя гөл чәчәк аткан.

# Көтә

Язлар җиту белән кошлар кайта,
Кайтмый калмый алар бер ел да.
Күрше карчык капка төпләрендә,
Карашлары аның зур юлда.

Маңгаена төшкән ак чәчләрен
Яулык асларына яшерә.
Кайтмады бит, бүген дә юк, диеп
Битен кайнар яше пешерә.

Сугыш беткәнгә дә илле биш ел,
И гомерләр бик тиз үтә шул.
Яу кырында ятып калган ирен
Тугры хатын шулай көтә шул.

# Көньякка карап уйланам

Моңсу көздә, җанга сагыш өстәп,
Кыр казлары очты көньякка.
Күзләремне яшь пәрдәсе каплап,
Карап калдым мин дә шул якка.

Авылымның көньягында зират,
Анда әткәм, әби-бабамнар.
Озатылды инде шул якларга
Күпме дуслар, күпме туганнар!

Язын кошлар кайтыр, ә үлгәннәр
Кайта алмый инде кирегә.
Кыр казлары булып алар рухы
Кайтадыр ул, димен, бирегә.

# Син юк, әткәй!

Чәчәк атты язын бакчабызда,
Әткәм, син утырткан алмагач.
Авыр икән, бигрәк авыр икән,
Ир балага әткәй булмагач!

Синең киңәшләрең, ярдәмнәрең,
Синең ныклы куллар бик кирәк.
Булыр иде авыр язмышыма,
Исән булсаң бүген бер терәк.

Коляскамда бакчабызга чыгам,
Чәчәк искәйләрен суларга.
Кереп кенә югалгандай булдың,
Их, әткәем, тирән суларга.

Бирешмимен, әткәй, өйрәнелде
Барчасына инде түзәргә.
Әл дә әнкәем бар яннарымда
Пешкән алмаларны өзәргә!

# Җырлап яшибез

Күзләремә кара, йөрәккәем
Бары сине генә үз итә.
Сөйгән кешең белән гел аңлашып
Яшәүләргә җирдә ни җитә!

Авырлыклар булмый гына булмый,
Җил-давылга яшик бирешми.
Авырлыкны җиңми генә беркем
Бөек максатына ирешми!

Без дә, иркәм, синең белән бергә
Күп каршылык күрдек, күрербез.
Гүргә кергәндә дә елап түгел,
Җиңүчеләр булып керербез!

Язмышларга рәхмәт, кавыштырды,
Беребезгә беребез тиңнәр без.
Бөтен авырлыкны елап түгел,
Җырлап кына, иркәм, җиңәрбез!

# Соңламыйк

Гармун моңнарына сусадык бит,
Авылыбыз белән без бергә.
Элеккедәй кичке урамнарда
Хәзер гармун моңы юк бердә.

Аулак өйләргә дә йөрү бетте,
Әткәйләрдәй тартып гармуннар.
Онытыла бара бабамнардан
Ядкарь булып калган бар моңнар.

Тасмалардар чит-ят көйләр генә
Тыңлый хәзер татар баласы.
Үз телендә димәк бишек җыры
Җырламаган аңа анасы.

Авыл урамнарын моңга күмеп,
Гармун алып җырлап без үтик.
Соң түгелдер, әйдә, соңлаганчы
Хаталарыбызны төзәтик!

Кәүсәрия Шафикова

# МИН КАНАТЛЫ

# Васыять

Коймалар, капка, тәрәзләр
Буяу күрмәгән күптән.
Хуҗасының җиң сызганып
Эшләр чаклары үткән.

Баганалар да кыйшайган,
Кыйгаеп бара өе.
Кадак-чүкеч тотучы юк,
Калыр инде шул көе.

Таякка таянган хуҗа,
Тора капка төбендә.
Балалары кайтып төшмәс
Микәнни соң бүген дә?

Кешеләргә гел ул әйтте:
Васыять бу, тотыгыз.
Нигезегез таралмасын,
Калсын берәр кошыгыз.

# Котлау

Шатлыкларым итеп җырлыйм бүген,
Уңыш биргән иген кырларын.
Кая гына басмыйм, шунда күрәм
Якташларның алтын кулларын.

Шәһәр үсә, үсә авыллар да,
Ут яктысы кара төннәрдә.
Чабаталы заман ерак калды,
Бар михнәте үткән көннәрдә.

Өстәлләрдә тәм-том, киемнең дә
Асылларын гына киябез.
Бүген дә без аллы-гөлле булып
Бәйрәм табынына киләбез.

Бар дөньяны кочып алам кебек,
Заңгәр күккә җәям колачым.
Шөкер, безгә насыйп булды күрү
Бу тормышның якты кояшын.

Гөл бакчасы булып яшә әле,
Кагылмасын сиңа җил-давыл,
Зур бәйрәмең белән, туган җирем,
Җитмеш яшең белән, Яңавыл!

* * *

Үткәннәр — сагышым,

киләчәк — хыялым,

Чайкала-чайкала баруым гел алга.

Яшәлгән еллардан, килер көн яктырак,

Әйе, ул ямьлерәк, ышанам хыялга.

Ай-һай күп күргәннәр, елаган-көлгән-

нәр,

Мин кат-кат санадым,

бу тормыш мең катлы.

Бер генә яшисе, егылдым, шуыштым,

Түбәндә түгелмен, хыялым канатлы.

* * *

Күзләрдә яшь, иреннәрне
Тешлисең.
Сөйләшеп тә булмый, әллә
Нишлисең.

Авыр сулап бер җиңеллек
Эзлисең.
Бер читкәрәк карап нидер
Күзлисең.

Күз алдында томан гына
Куера.
Җанны нидер өтеп ала,
Куыра.

Егар кебек җилләрнең дә
Исүе.
Саубуллашу бу, йөрәкнең
Үксүе!

* * *

Киләчәктә — үлем, кирәк әле
Үлгәнчегә кадәр яшәргә.
Күкрәүләре булыр, бу дөньяны
Балкытканчы кирәк яшьнәргә.

Дөнья якты, дөнья кояшлы ул,
Нур өстәлсен аңа миннән дә.
Ак өметле булган әнкәм күңеле,
Мин гаиләнең тәүге нарасые,
Бу дөньяга елап килгәндә.

Өметеңне мин аклармын, әнкәй!

* * *

Җил алды да җиргә бәрде
Агачтагы ояны.
Көтелмәгән бу фаҗига
Дер селкетте дөньяны.

Исән калган бер кошчыкның
Сынган очар канаты.
Аерылган гаиләләрне
Искә төшерде бу оя,
Йөрәккәйне канатты!

# Көчле ул

Кошлар әйтә: очалмыйсың,
Юк синең канатларың!
Ә кеше белә үзендә,
Белә ул канат барын.

Кош канаты каерыла
Җил-давыл көче белән.
Тиңләшә алмыйдыр кошлар
Бу хәлдә кеше белән?!

Канатлары имгәнсә дә,
Юк, кеше өмет өзми—
Кош юлыннан күзен алмый,
Үзенә бер генә бөртек
Бәхет каурые эзли.

Эзләгәнен табып ала,
Көчле ул кеше, көчле.
Яшәүгә булган сөюдән
Ала ул бөтен көчне!

# Рәхмәт, дуслар!

Язны сагынып көткәнемне
Каян белдегез?
Назлы язның бөтен ямен
Алып килдегез.

Минем өчен өзелгән бу
Умырзаялар.
Чәчәкләр нәкъ үзегез күк,
Шат, елмаялар.

Сездә күрәм яз яктысын,
Тоям җылысын.
Бүләк иттегез җаныма
Язның җырлысын.

Күңелемдә яз кояшы,
Кулымда — чәчәк!
Уйларымда — балкып торган
Сезнең киләчәк!

* * *

Бу дөньяның һәркем өчен
Бар кайгысы, шатлыгы.
Бездә имән ныклыгы бар,
Каеннарның аклыгы.

Авырлыктан бөгелмибез,
Кысылган безнең тешләр.
Кыенлыклар безнең алда
Җиңелеп калмый, нишләр?!

Гөлләрдән алдык матурлык,
Кошлардан алдык канат.
“Мескеннәр!”- дип, йә, кем әйтер
Безнең күзләргә карап?!

Таулар итеп күтәрерлек
Булмаса да эшебез.
Елап түгел, бу тормышка
Бер ямь булып, көлә-көлә
Яши белгән кеше без!

* * *

/Мәктәп тәмамлаучыга/

Мәктәп кала, очар канатларың,
Ерак алып китәр, мөгаен.
Ак теләкләр генә теләп кала
Мәктәп янындагы ак каен.

Дәшеп тора гүзәл хыялларың,
Изге эшләр кылә кыласың,
Килә синең батырлардан батыр,
Матурлардан матур буласың.

Кыңгыраулар чыңы яшәр синдә,
Үткән еллар моңы ул чыңнар
Төшләреңә кереп сагындырыр
Кире кайтмый торган ул еллар.

Мәктәбеңнән чыккан юлың сине,
Зур тормышка алып китәчәк.
Тик исеңнән чыгармачы, бала,
Иманына тугры булганнарны
Кабул итә якты киләчәк!

* * *

Тамчылар, көмеш тамчылар,
Йөрәгемә тамдыгыз.
Йөрәгемә тамдыгыз да
Ялкын булып яндыгыз.

Җырларыма әйләнеп сез
Язга кабат кайттыгыз.
Язда сезнең сафлыгыгыз,
Язда сезнең яктыгыз.

Тере су булып сез җанга
Тамасыз тамчыкайлар.
Тамчылар тамган чак бит ул,
Бер түгел, мең үлемеңнән
Терелтә торган айлар.

# Үсмер кызларга

Сабан туе җитә, кызлар.
Кызлар, ишетәсезме?
Карагыз, сабан туйларда
Егетләр сыный сезне!

Кулъяулыклар чиктегезме,
Чиктегезме сөлгеләр?
... Җаваплары шулдыр инде,
Кызлар миннән көлделәр.

Юк, үсмер кыз миннән түгел,
Ул бит үзеннән көлә.
Беләм гашыйк егетенә
Матур күренәсе килә.

Әнә көзге каршында
И буйый битен-күзен.
Ничек матур күрсәтергә
Белми шул, белми үзен!

# Кунакка кайткан берәүгә

Сиңа, авылдашым, диеп,
Ничек эндәшим?
Урысчалатып әйтәсең:
“Городта яшим,
Только погастить приехал,
Тиздән уеду.
Авылда тудым и үстем,
Приезжать буду.
Шумный город ждет меня,
Авылда калмыйм.
Да, скучно, но, бөтенләй
Юк кайта алмыйм!”
Телсез булып кайткансың бит,
Нишләдең, бәндәм?
Үзең тоймыйсыңдыр, син бит
Кызганыч хәлдә!
Анаң да, авыл да сиңа
Ятсынып бага:
И бала!.. Бала!..

* * *

Кеше хәлен кеше белсен иде,
Үз башына төшми белми шул.
Кайгы күрмәгәннәр алдында син
Башкаеңны күтәр, горур бул.

Күзләреңнең яшен күрмәсеннәр,
Сиңа гына аның ачысы
Бөгелеп төшмә әле "авыр" диеп,
Кайгыларның җиңел кайсысы?!

Хәлләремне беркем аңламады,
Көчле санап күзгә бактылар.
Түзә белүемне үзләренә
Яшәү көче итеп таптылар!

* * *

/Илдар белән Диларага/

Унҗиде яшь ал чәчәкнең
Яңа гына ачылганы!
Чәчәк таҗын Ләйсән убә,
Йомшак җилләр назлый аны.

Унжиде яшь, гашыйк булып
Ялкыннарда көя башлау.
Дөньяга ямь, шатлык өстәп,
Өзелеп-өзелеп сөя башлау!

Унҗиде яшь — хыялларда
Бәхет-тауга үрләгән чак.
Ә чынында, чынбарлыкта
Ак-караны күрмәгән чак!

* * *

Татар авылында туды,
Татар ата-анасы.
Тик үзенең әйткәне юк,
Мин дип татар баласы!

Татарча ачылды теле,
Инде сөйләшә белми.
Татарча җыр да тыңламый,
Татар буласы килми.

Күзләренә карап торам,
Нидер сөйли, тыңламыйм.
Уйлыйм, адашкан юлыннан
Ничекләр тартып алыйм?!

“О боже!”-ди бит, әйтерсең
Юк үзенең Алласы.
Саташып шулай озакмы
Йоклар татар баласы?

* * *

Әйтерсең лә мин бер җинаятьче,
Богауланган аяк-кулларым.
“Кузгалма!”- дип язмыш боерса да,
Дәшеп ала үтәр юлларым.

Кырга чыгып рәхәт сулыш алам
Тургайларны тыңлыйм тын калып.
Төнбоекка тулы, бөдрә таллы
Су буенда калам тукталып.

Салкын чишмә суын авыз итәм,
Имәнлектә агып ята ул.
Калатауга бармый каламмы соң,
Бала чактан миңа таныш юл!

Кулларымда ялан чәчәкләре,
Иңнәремдә талгын җил генә.
Сәхрәләрдә хәлем арулана,
Авырлыклар шунда җиңелә!

Коляскамнан төшеп йөгерәм кебек,
Шатлыкларга юк ул үлчәүләр!

Рәхмәт яусын фәрештәләремә
Янәшәмдә алар өчәүләр—
Илдар,
Дилара,
Дания!

* * *

Бер матур уенчыгыңны
Ватмыйча сакла бала.
Уенчыклы еллар берчак
Еракта торып кала.

Төшләремә дә кермәде
Синдәге уенчыклар.
Күзләремне кызыктыра
Син уйнаган курчаклар.

Ерак елларымнан килдем,
(Син миңа дәшмисең дә).
Ни булсын, пыяла тәтәй
Күлмәгем кесәсендә...

Әле йөгереп килер кебек,
Шул сабый вакытларым.
Кызыксам да курчагыңа,
Тик кадерлерәк шул миңа
Чынаяк ватыклары!

18-19 март 1986 ел.

* * *

Бу — дөнья, шушы дөньяга
Тудырган сине ана.
Эчәсең килсә, чишмә бар,
Өшесәң, учак яна.

Менәргә дисәң, бар тавы,
Өзәргә гөле үсә.
Давылы алса хәлеңне,
Иркәләп җиле исә.

Бар да бар, чыга кояшы,
Яңгыры ява, кары.
Дөнья зур, азсынма, яшәү
Бер мизгел генә бары.

Бер гомер өчен анаңа
Мең рәхмәт әйт син, бала.
Дөньяга сине тудырып,
Ул җанын утка сала.

# Яшьләргә

Талгын җилдә тирбәләләр
Хуш исле ак тәлгәшләр,
Шушы ап-ак чәчәкләрне
Өзә күрмәгез, яшьләр!

Аклык — сезнең сафлык бит ул,
Тормышта сафлык кирәк.
Аклыкка таплар төшмәсен,
Җаннарга шатлык кирәк!

Шомырт чәчәк аткан чакта,
Гел сезне уйлыйм, яшьләр!
Бар да ал да гөл түгел бит,
Күзләргә килә яшьләр.
Белегез, җимеш өлгертә
Өзелмәгән тәлгәшләр!

# Көтәм

Гөл тәрәздән күзен алмый
Кояшына баккан.
Кояштан шул, гөл кояштан
Яшәү көче тапкан!

Минем дә күзләр тәрәздә,
Ә көткәнем — ул син!
Тормышымда аллы-гөлле
Гөл үстерер нур син!

# Апрель

Иң матур шигырем язылыр, дип,
Ашкынып и көттем яз аен.
Көннәрең кояшлы булса да
Китердең кайгының таудаен!

Җилләрең кочса да иңнәрдән,
Наз итеп тоймадым үзләрен.
Сызылып таң атты, әнкәем,
Мәңгегә йомганда күзләрен!

Гомерем буена үксермен,
Су белән тулганда биек яр.
Бирешмәм, беренче гөлләрең
Юатыр, кулымда каләм бар!

* * *

Шатлыктан язылa шигырь,
Язылa кайгыдан да.
Өлешсез калмадым, шөкер,
Барысы да бар җанымда.

Шатлыктан туган шигырьдән
Табарсыз яшәү көчен.
Кайгыдан язылганнары—
Кайгымны җиңәр өчен.

## Мин җил генә түгел

Кояшымны каплый кара болыт,-
Күрәчәгем керә төшемә!
Төшләремдә түгел, өннәремдә
Таралыр ул болыт, мин ышанам
Давыллардан алган көчемә!

* * *

/Рәфискә/

Былбыл сайраганда түгел,
Кыш аенда тугансың.
Шуңадыр, дим, Ай-Кояшлы,
Ак хыяллы булгансың.

Гөлләр үскән чакта түгел,
Кар яуганда тугансың.
Ак чәчәкле сөю булып,
Бар дөньяма тулгансың.

Туган көнең белән котлап
Юллыйм йөрәк җырымны.
Бүләк итәм, гомер кышың
Җиткәндә дә күңелеңә
Яз китерер җылымны!

# Туй

Ишегалды тулы халык,
Әллә туймы соң монда?
Әйе, туй, Чечня җиреннән
Туган җиргә кайтып төште
Яшь солдат табутында!

Исем туе булган иде,
Бу инде соңгы туе.
Туй итәргә өлгермәгән
Мәхәббәт кызның йөрәген
Елатыр гомер буе!

# Канатлар

Әле канат чыгарасыз,
Очар көнегез җитәр.
Һәркайсыгыз үзе сайлап
Алган юл белән китәр.

Шуны әйтәм: бу тормышта
Кыенлык очрый калса,
Өзгәләсә, җаныгызга
Утлар китереп салса,

Биеклектән сикермәгез,
Эзләмәгез бавын да...
Канатлар ныгый гына ул
Калган саен давылда!

# Бар шундый мәхәббәт...

Өзгәләп ташланган чәчәкләр күрәм дә,
Өзелеп и үкси күңелем кыллары.
Гомерлек яралы, терелмәс чәчәкләр
Сез бит ул, ирекле мәхәббәт коллары!
Кызганам мин сезнең
кадерсез яшьлекне,
Чәчи ул сигара һәм хәмер исеннән.
Төзәтә алмаслык хаталар күп анда,
Мәхрүм бит ялкынлы,
саф сөю хисеннән!
Тугач та чүплеккә ташланган сабыйлар,
Бер генә көнгә дә
чыкмый шул исемнән!

# Көзге янында

Нигә әле, агарды, дип
Чәчләремне буярга.
Ефәк кебек чәчләремә,
Буяу сылап куярга?!

Менә ул минем чын йөзем,
Юк анда ясалмалык.
Диңгез ярында, юк, сине
Чакырмыйм, алтын балык.

Үз-үземне алдый-алдый,
Эзләмим яшьлек төсен.
Акыл утырткан яшьтә мин,
Йөзем нигә кызарсын ди,
Ап-ак чәчләрем өчен!

* * *

Кояшлы яуган яңгыры,
Наз гына искән җиле.
Кошлар моңына бөгелә
Талларның нечкә биле.

Күк зәп-зәңгәр, җир ямь-яшел,
Чикләрне белми шатлык.
Төймә кадәрле дә тап юк,
Тантана итә сафлык!

Ни халәт, дөнья ямь генә
Бирер ялкынга тулган?
Беләм, яз гына түгел бу,—
Кыз бала гашыйк булган.

# Туган җирем

Туган җирем, ямьле Башкортстан,
Якты көнгә илтә юлларың.
Күз алдымда үсә Салаваттай
Ат атланып чабар улларың!

Туган җирем, яшел Башкортстан,
Сәхрә гөле синең кызларың.
Шигырь язам менә, кәгазь итеп
Ак каенның ефәк тузларын!

Туган җирем, җырлы Башкортстан,
Тарих сөйли моңлы кураең.
Игенең тулы кырда әйтерсең мин
Күккә очкан сабан тургаең.

Башкортстан, тезсәм матур сүзләр,
Шагыйрә бит, димә, сүзем хак!
Ак канатлы минем күңелем ул,
Агыйделне кочкан акчарлак!

* * *

Әйе, мин ялгыз калмадым,
Үземә тиң яр таптым.
Өлешем булган тормышымның
Татлы җимешен каптым.

Кызлар, ышаныгыз миңа,
Юк, мин бөти такмадым.
Юлларымнан язмас өчен,
Иманымны югалтмадым,
Сафлыгымны сакладым!

* * *

Пип-пип килгән и бәләкәч,
Синнән чынлап көнләшәм.
Җиле-яңгырлары белән
Инде күпме көрәшәм!

Сабый чакта гына түгел,
Әни кирәк икән гел.
Канат астындагы бәбкә,
Иркәлекнең кадерен бел!

* * *

Уфтанмыйм бер тамчы да,
Авыру булдым, диеп.
Кунакка килдем, йөримен,
Күңелем белән биеп.

Биимен дә, җырлыймын да,
Бүгенге көнгә шөкер.
Мәйданга чыгалмасам да,
Көчле икәнемне күр!

Шатлык дулкыннары бәреп,
Чыңлап китә күңел-кыл.
Сеңелемә апа булып
Яшәдем бит илле ел!

# ...(өч яше дә тулмаган Илгизгә)

Нәни бармаклары белән
Илгиз җиләкләр өзә.
Шундый татлы җиләкләрне
Ничек ашамый түзә!

Үрелеп миңа каптыра
Җиләкләрнең кызылын.
Сабый аңлый: Иркә апа
Күтәрә алмый кулын.

И шатлана, рәхмәтемне
Әйтәм мин җиләк саен.
Үскәч тә ул кешеләргә
Гел изгелек кенә кылып
Яшәр әле, мөгаен!

# Күчтәнәчем

Бар эшемне читкә куеп
Чыктым көзге бакчага.
Шушы матурлыкны алып
Булмый хәтта акчага!

Мондагы гүзәллек, байлык,
Кайда булсын, ди тагын!
Күңел сөенә тапканга
Көзнең иң җырлы чагын.

Әллә ничә өләшсәм дә,
Балан, миләш, алмасын
Быел да җырлыйм, дусларым,
Күчтәнәчсез калмассыз!

* * *

Нинди генә авырлыклар
Сынамый кемнәр өчен!
Ходай миңа кайгы биргән
Көчемне сынар көчен.

Эш авыр, дип зар елыйсың,
Мин тешләремне кысам.
Тормышның ни яме булыр,
Мин дә бер елак булсам.

* * *

Ярала икән мәхәббәт,
Бергә булыр өчен гел.
Азга гына саубуллаштык,
Канатсыз калды күңел.

Зәңгәр күккә күтәрелер
Кош идем кичә генә.
Ялгызым түзәм тормышның
Каршы искән җиленә.

Парсыз калганнарның хәле
Авыр икән лә бигрәк.
Соң түгел әле, соң түгел,
Мәхәббәтне рәнҗетмичә
Яши белергә кирәк!

* * *

Ак чәчәк кебек бер кызның
Елаганын күрдем дә,
Түзмәдем, күңелем тулып
Еладым мин үзем дә.

Беләм бу сылуның нигә
Күз яшьләрен түккәнен.
Сөйгәнен күргән янәшә
Бер кыз белән үткәнен.

Әй, ул йөрәк хәтерләтә
Дөрләп янган учакны.
Кызга карап күреп торам
Үземнең үсмер чакны!

# Бала күңеле

Бала күңеле якты киртә кебек,
Гел кояшлы аның хыяллары.
Аллы-гөлле тасма нурлар чәчә
Киләчәккә илтә зур юллары.

Бала күңеле белми явызлыкны,
Гел күбәләк инде, уйный-оча
Матурлыктан гына тора, диеп
Уйлый, ахры, бар дөньяны коча.

Бала күңелендә гел җылылык,
Өшегәндә якын килеп була.
Бала күңелендә тирән сафлык,
Бер рәхәтлек табып аның белән
Бергә елап, бергә көлеп була.

* * *

Һич китәсем килми синнән, якты дөнья,
Тик нишлисең, бар да китә,
бер мин калмам.
Килер ул көн, ләкин матур хыялымны,
Җир куенына үзем белән бергә салмам.
Бер гүзәллек тудырасым килеп яшим,
Яралыр ул акыл, көч һәм сабырлыктан.
Ул, мөгаен, җырым булып яңгырар әле,
Һәм җыр әйтер:
"Курыкмагыз авырлыктан!
Курыкмагыз авырлыктан!"

ЭЧТӘЛЕК:

Тирәк . . . . . . . . . . . . . . 5
Таркалдылар . . . . . . . . . . 6
Туган ягыма . . . . . . . . . . 7
/Апама/ . . . . . . . . . . . . . 8
Юк, башымны имәм . . . . . . 9
Гомер телим . . . . . . . . . . 10
Авылыма . . . . . . . . . . . . 11
Бәхет нуры . . . . . . . . . . . 12
Карлар ява . . . . . . . . . . . 13
Илемә илле бишенче... . . . . 14
Җиңәргә! . . . . . . . . . . . . 15
Яшә! . . . . . . . . . . . . . . 16
Туган көнем . . . . . . . . . . 17
Зурлага охшарга теләп... . . . 18
Сәбәп . . . . . . . . . . . . . 19
Әни . . . . . . . . . . . . . . 20
Нәни тербиясе биреп карый ... . 21
Давыллы чак . . . . . . . . . . 22
Көн дә убыр, алкаш, эчеп... . . 23
Мин дә бәхетле . . . . . . . . 24
Нишләр иде? . . . . . . . . . . 25
Авыл юллары таш, асфальт... . 26
Шәһәрдә авылга кайтты... . . . 27

Шәһәр урамыннан барганда . . . 28
Иртәнге җыр . . . . . . . . . . . 29
Ямьсезлек . . . . . . . . . . . 30
Эш узгач . . . . . . . . . . . 31
Гәзиттә бер сурәт, анда сабый... . 32
Заман белән көрәш. . . . . . . . 33
Яңа ел каршылаганда . . . . . . 35
Китмә, әнкәй! . . . . . . . . . . 36
Йөзләреңә карап-карап куям... . . 37
Кичә генә кап-карадан идең... . . 38
Чишмәләргә кушылып күңел
елый. . . . . . . . . . . . . . . 39
Берәм-берәм китәбез шул... . . . . 40
Урам эте . . . . . . . . . . . . 41
Яз килгән, яз, урамнардан... . . . 42
Көтә. . . . . . . . . . . . . . . 43
Көньякка карап уйланам . . . . 44
Син юк, әткәй! . . . . . . . . . 45
Җырлап яшибез . . . . . . . . . 46
Соңламыйк . . . . . . . . . . . 47
Васыять . . . . . . . . . . . . 49
Котлау . . . . . . . . . . . . . 50
Үткәннәр — сагышым,
киләчәк — хыялым... . . . . . . 51

Күзләрдә яшь, ирennәрне
тешлисең... . . . . . . . . . . . 52
Киләчәктә — үлем, кирәк әле... . 53
Җил алды да җиргә бәрде.... . . . 54
Көчле ул . . . . . . . . . . . . . 55
Рәхмәт, дуслар! . . . . . . . . . . 56
Бу дөньяның һәркем өчен... . . . 57
/Мәктәп тәмамлаучыга/. . . . . . 58
Тамчылар, көмеш тамчылар... . . . 59
Үсмер кызларга . . . . . . . . . . 60
Кунакка кайткан берәүгә . . . . . 61
Кеше хәлен кеше белсен иде... . . 62
/Илдар белән Диларага/. . . . . . 63
Татар авылында туды.... . . . . . 64
Әйтерсең лә мин бер җинаятьче... 65
Бер матур уенчыгыңны... . . . . . 67
Бу — дөнья, шушы дөньяга... . . . 68
Яшьләргә. . . . . . . . . . . . . 69
Көтәм . . . . . . . . . . . . . . 70
Апрель. . . . . . . . . . . . . . 71
Шатлыктан язылa шигырь.... . . . 72
Мин җил генә түгел . . . . . . . 73
/Рәфискә/ . . . . . . . . . . . . 74
Туй . . . . . . . . . . . . . . . 75

Канатлар . . . . . . . . . . . . . 76
Бар шундый мәхәббәт... . . . . . 77
Көзге янында . . . . . . . . . . . 78
Кояшлы яуган яңгыры... . . . . . 79
Туган җирем . . . . . . . . . . . 80
Әйе, мин ялгыз калмадым... . . . 81
Пип-пип килгән и бәләкәч... . . . 82
Уфтанмыйм бер тамчы да... . . . . 83
...(өч яше дә тулмаган Илгизгә) . 84
Күчтәнәчем . . . . . . . . . . . . 85
Нинди генә авырлыклар... . . . . 86
Ярала икән мәхәббәт... . . . . . . 87
Ак чәчәк кебек бер кызның... . . . 88
Бала күңеле . . . . . . . . . . . 89
Һич китәсем килми синнән,
якты дөнья... . . . . . . . . . . 90

